# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлеге
Чупай торак пунктында 2025 елда гражданнардан
үзара салым кертү турында

**29.11.2024ел** **№ 22**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге Чупай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге Чупай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

1) Чупай торак пункты территориясен төзекләндерү (хуҗасыз кишәрлекләрдә койма урнаштыру өчен төзелеш материаллары сатып алу);
2) Чупай торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Мөшеге елгасы аша җәяүлеләр күперенә култыксалар кую (төзелеш материаллары сатып алу).

3. Әлеге карарны Әтрәкле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы ______________ А.М. Гильмуллин